КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 4 июль г.Казань № 548

Сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм технопаркларның җитештерү һәм инновация компанияләрен булдыру (үстерү) максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җитештерү мәйданнарыннан һәм урыннарыннан ташламалы файдалана алу мөмкинлеге бирүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм (яки) технопаркларның идарәче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру максатларында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Икътисадый үсеш һәм инновацион икътисад» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 316 номерлы карары белән расланган «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары акселерациясе» федераль проекты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм технопаркларның җитештерү һәм инновация компанияләрен булдыру (үстерү) максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җитештерү мәйданнарыннан һәм урыннарыннан ташламалы файдалана алу мөмкинлеге бирүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм (яки) технопаркларның идарәче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин